| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 13 » 12 2021 № 412

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге
тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында» 2020 ел,
13 октябрь, 646 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 ел, 27 июль, 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләрен, хезмәт күрсәтүләрне, электрон формада дәүләт йөкләмәсен (заказын) урнаштыра торган социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» 2021 ел, 13 апрель, 242 нче карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 ел, 26 ноябрь, 651 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 ел, 13 октябрь, 646 нчы карарына (12.01.2021. №3; 01.07.2021 № 208; 01.07.2021, № 210; 27.07.2021, № 235; 30.07.2021, № 239 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1.1, 1.6, 1.20, 1.21 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

- «1.1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алуга (төзүгә) учетка кую һәм социаль

түләү алуга хокук турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта)»;

- «1.6. Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә, сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нче кушымта)»;

- «1.20. Җирлекнең (шәһәр округының) Генераль планыннан яисә җирләрдән файдалану һәм Төзелеш алып бару кагыйдәләреннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (20 нче кушымта)»;

- «1.21. Юл билгеләрендә индивидуаль проектлауның мәгълүмати билгеләре урнаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (21 нче кушымта)».

- «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алуга (төзүгә) учетка кую һәм социаль түләү алуга хокук турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 1 нче кушымтасын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

- «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә, сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 6 нчы кушымтасын әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

- «Җирлек территориясе өстеннән авиация эшләрен, парашют сикерүләрне, һава судноларының демонстрацион очышларын, пилотсыз очу аппаратлары (0,25 кг. нан кимрәк очыш массасы булган пилотсыз очу аппаратларының очышларыннан тыш) очышларын, бәйләүле аэростатларны очырыга рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 10 нчы кушымтасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

- «Җирлекнең (шәһәр округының) Генераль планыннан яисә җирләрдән файдалану һәм Төзелеш алып бару кагыйдәләреннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 20 нче кушымтасын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә

- «Юл билгеләрендә индивидуаль проектлауның мәгълүмати билгеләре урнаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 21 нче кушымтасын әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм милек белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ОГРН 1601665000550
ИНН 1603004720 КПП 160301001